| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2017 Казан ш. № 5-89/тэ

«Су үткәрү-канализацияләү һәм энергетика хуҗалыгы» акционерлык җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләренә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.11.2015 № 5-56/тэ карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2018 ел өчен үзгәрешләр кертү хакында

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә һәм 2018 елга җайга салынучы оешманың планлы зарури тулай табышын тәгаенләштереп, җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләренә дәвамлы тарифларга 2018 ел өчен үзгәрешләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Су үткәрү-канализацияләү һәм энергетика хуҗалыгы» акционерлык җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләренә 2016-2018 елларга тарифлар билгеләү турында» 30.11.2015 № 5-56/тэ карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.12.2016 № 5-76/тэ карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтага, шушы карар кушымтасына туры китерелгән яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2017 № 5-89/тэ карарына кушымта
«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.11.2015 № 5-56/тэ карарына 1 нче кушымта

«Су үткәрү-канализацияләү һәм энергетика хуҗалыгы» акционерлык җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләренә 2016-2018 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

<table>
<tr><th rowspan="2">№ п/п</th><th rowspan="2">Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы</th><th rowspan="2">тариф төре</th><th rowspan="2">Ел</th><th colspan="2">Җылысаклагыч төре</th></tr>
<tr><th>су</th><th>пар</th></tr>
<tr><td></td><td colspan="5">Түбән Кама муниципаль районы</td></tr>
<tr><td rowspan="7">1</td><td rowspan="7">«Су үткәрү-канализацияләү һәм энергетика хуҗалыгы» акционерлык җәмгыяте</td><td colspan="4">Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен</td></tr>
<tr><td rowspan="6">Бер ставкалы, сум/Гкал</td><td>01.01.2016 башлап 30.06.2016 кадәр</td><td>407,81</td><td>-</td></tr>
<tr><td>01.07.2016 башлап 31.12.2016 кадәр</td><td>413,75</td><td>-</td></tr>
<tr><td>01.01.2017 башлап 30.06.2017 кадәр</td><td>413,75</td><td>-</td></tr>
<tr><td>01.07.2017 башлап 31.12.2017 кадәр</td><td>454,52</td><td>-</td></tr>
<tr><td>01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр</td><td>440,93</td><td>-</td></tr>
<tr><td>01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр</td><td>456,42</td><td>-»</td></tr>
</table>

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге